| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ГОРОДА БУИНСКА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БУА ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» февраль 2015ел № 18

**«Буа шәһәренең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлекләрен раслау хакында»**

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 7 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2015 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә Буа шәһәре Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлекләрен 1, 2 кушымталар нигезендә расларга.
2. Билгеләргә:

- Мәгълүматны Интернет челтәрендә урнаштыру вакыты - җиде календарь көнгә кимендә бер тапкыр (урнаштырылырга тиешле мәгълүмат булган очракта) урнаштыру вакыты.
- яңарту сроклары - аена бер тапкырдан да ким түгел.

3. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә һәм Буа муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырылырга тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Буа шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе А.А. Никифоров